**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аларның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында

Йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү очрагы ачыклану һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2006 елның 27 мартындагы 90 номерлы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы вирусы барлыкка килүгә бәйле рәвештә, аларны бетерү турында карар кабул ителгәнгә кадәр, чикләү чараларын (карантин) кертергә:

Чүпрәле районының Яңа Чүпрәле авылы янындагы «Төхфәтуллин Фәнис Махсут улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан йорт кошлары асрау өчен файдаланыла торган ферма территориясенең бер өлеше;

Мөслим районы Дусай авылы янындагы гражданин Р.Р. Шакирҗанов тарафыннан йорт кошлары асрау өчен файдаланыла торган җир кишәрлеге территориясенең бер өлеше.

2. Татарстан Республикасының әлеге Указның 1 пункты нигезендә билгеләнгән аерым территорияләрендә кош-кортның, кошчылык продуктларының, азык һәм азыкка өстәмәләрнең әйләнешенә кертелгән чикләүләрнең кушымтада бирелүче исемлеген, аларны бетерү турында карар кабул ителгәнгә кадәр, расларга.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләре (алга таба – имин булмаган пунктлар) чикләрендә эпизоотия чыганакларын;

б) имин булмаган пунктлар чикләреннән 5 км радиустагы территория кысаларында Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктларын кертеп, куркыныч янау зонасын:

Чүпрәле районының Яңа Чүпрәле авылын, Иске Чүпрәле авылын, Хайбулдино авылын, Чуаш Чүпрәлесе авылын, Иске Әлмәле авылын, Кушкуак авылын;

Мөслим районының Дусай авылын, Баек авылын, Яңа Карамалы авылын, Яңа Сәфәр поселогын, Әндереш авылын, Карл Либкнехт исемендәге авылны;

в) имин булмаган пунктлар чикләреннән 10 км радиустагы территория кысаларында Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктларын кертеп, күзәтү зонасын:

Чүпрәле районының Алешкин-Саплык авылын, Иске Задур авылын, Яңа Задур авылын, Иске Әлмәле авылын, Иске Чокалы авылын, Яңа Чокалы авылын, Чуаш Бизнәсе авылын, Татар Бизнәсе авылын, Матак авылын, Чуаш Ишлесе авылын, Иске Ишле авылын, Яңа Ишле авылын, Татар Саплыгы авылын;

Мөслим районының Горбуновка авылын, Покровка авылын, Октябрь авылын, Иске Карамалы авылын, Бәкәбез авылын, Күбәк авылын, Түреш авылын.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йогышлылыгы югары булган кош гриппы вирусы чыганагын бетерү һәм авыру чыганагының Татарстан Республикасы территориясендә таралуын булдырмау буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 28 октябрь
№ ПУ-715

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның « 28 » октябрендәге
ПУ-715 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә кош, кошчылык продуктлары, азык һәм азыкка өстәмәләр әйләнешенә кертелгән чикләүләр исемлеге**

Чикләү чаралары (карантин) гамәле вакытында имин булмаган пунктлар территорияләрендә:

территориягә чит кешеләр керүне һәм транспорт керүне туктатырга;

турыдан-туры хезмәт күрсәтүче персоналдан һәм чаралар уздырыла торган вакытка өстәмә рәвештә объектка беркетелгән ветеринария өлкәсендәге хезмәткәрләр һәм белгечләрдән тыш, имин булмаган пунктка чит кешеләр керүне тыярга;

кошларның имин булмаган төркеменә хезмәт күрсәтүче персоналның оешма территориясе буйлап йөрүен чикләргә, аларның башка кошлар һәм аларга хезмәт күрсәтүче затлар белән аралашуын булдырмаска;

чир йоктырган кошларны кан чыгармыйча юк итүне, үлгән һәм юк ителгән кошларны герметик тарага җыюны оештырырга;

кан чыгармыйча массачыл төстә кошларны юк итү вакытында, авыру тудыручы дип күздә тотылган чыганакның әйләнә-тирә мохиттә таралуын булдырмау шартларында, үләксәләрне күмүне билгеләнгән тәртиптә уздырырга;

имин булмаган пунктлар эчендә кошларны күчерүне һәм алардан кошларны, йомыркаларны һәм башка кошчылык продуктларын, шулай ук кош азыгы, эш коралларын, җиһазларны, кош тизәген чыгаруны туктатырга;

йорт кошлары булган башка хуҗалыкларга керүне, кошларны һәм кошчылык продуктларын, эш коралларын, җиһазларны, кош тизәген чыгаруны туктатырга;

имин булмаган пунктлар чигеннән кошларны чыгаруны һәм аларны башкача файдалануны туктатырга;

кош сатуны вакытлыча туктатырга;

имин булмаган пунктлардан чыгу юлларын (сукмакларны) ябарга, кирәкле санда дезинфекцияләү киртәләре, кием-салымны эшкәртү өчен пароформалин камералары һәм дезинфекцияләү җайланмалары белән җиһазландырылган тәүлек әйләнәсе кизү торачак контроль-үткәрү постлары куярга, аларда эшләргә ветеринария инспекторларын һәм хокук саклау органнары хезмәткәрләрен җәлеп итәргә;

карантин зоналарында транспорт хәрәкәтен чикләргә, шул исәптән керү рөхсәт ителгән транспорт карантин зонасына узганда һәм аннан чыкканда мәҗбүри дезинфекцияләнергә тиеш;

авыруларга аеруча бирешүчән баш санын сую һәм юкка чыгару буенча чаралар уздырырга.

---